ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.10.2020 г. Заинск № 441

**«Муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә социаль ярдәм чаралары турында" 2006 елның 19 декабрендәге 1642 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

Авыл җирлегендә эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 18 июлендәге 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә социаль ярдәм чаралары турында» 2006 елның 19 декабрендәге 1642 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«- авыл торак пунктларында яшәүче һәм эшләүче белем бирү оешмалары җитәкчеләренә, аларның урынбасарларына, белем бирү оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм урынбасарларына.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Л.Р. Печина
3-27-42